# КАРАР

**“07” ноябрь 2020 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Наласа авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 07 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлек территориясен төзекләндерү:

- Наласа авылында рөхсәтсез чүплек урнашкан урыннарда җирләрне рекультивацияләү;
- Наласа авылының Яшьләр урамында агачларны санитар кисү, чыгарып ташлау һәм территорияне чистарту;
- «Таш Чишмә», «Рабига чишмәсе» территорияләрен төзекләндерү һәм «Рабига чишмәсе»ннән Наласа авылына суүткәргеч торбалар салу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 502 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 261 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 261 кеше тавыш бирде;
“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә Наласа авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2 «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлек территориясен төзекләндерү:

- Наласа авылында рөхсәтсез чүплек урнашкан урыннарда җирләрне рекультивацияләү;
- Наласа авылының Яшьләр урамында агачларны санитар кисү, чыгарып ташлау һәм территорияне чистарту;
- «Таш Чишмә», «Рабига чишмәсе» территорияләрен төзекләндерү һәм «Рабига чишмәсе»ннән Наласа авылына сууткәргеч торбалар салу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов урамы, 64 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова